КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2018 ел, 13 сентябрь г.Казань № 777

2019 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен расларга.

2. Бу карарның 1 нче пункты белән расланган социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре барлык милек рәвешләрендәге һәм ведомство буйсынуындагы мәгариф оешмаларында эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары, урта звено белгечләре әзерләү программалары, бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча белем ала торган укучыларга кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 681 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 13 сентябрь, 777 нче
карары белән расланды

2019 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре

Т/с	Социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр исеме	Түбәндәге программалар буенча белем алучыларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләме, сум				
		эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү	төп гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү	урта гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү	урта звено белгечләрен әзерләү	бакалавриат, специалитет, магистратура
1	2	3	4	5	6	7
1.	Белем бирү оешмасын тәмамлап чыкканда ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга бер тапкыр бирелә торган пособие	753	753	753	753	753
2.	Белем бирү оешмасын тәмамлап чыкканда ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку	59337	59337	59337	59337	59337

1	2	3	4	5	6	7
	чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие					
3.	Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга уку әдәбияты һәм язу өчен кирәк-яраклар сатып алуга еллык пособие	-	2693	2693	2693	6969
4.	Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие	25289	25289	25289	25289	25289
5.	Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга белем алучылар өчен 2018 елның 1 сентябренә кадәр билгеләнгән стипендия күләменнән артмаган күләмдә айлык стипендия	-	891	891	891	891
6.	Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм	-	930	930	930	930

1	2	3	4	5	6	7
	калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга белем алучылар өчен 2018 елның 1 сентябреннән билгеләнгән стипендия күләменнән артмаган күләмдә айлык стипендия					
7.	Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга туклану өчен айлык пособие	6611	6611	7618	7618	7618